СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 99 12.04.2017

№ _________от ______________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты
турында

2014 елның 19 декабрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга туры китерү һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Россия Федерациясе Законының 44 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын яңа редакциядә кабул итү турында» 2014 елның 19 декабрендәге 281 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча «Саба муниципаль районында гавами тыңлаулар турында нигезләмә проекты хакында» 2006 елның 21 октябрендәге 94 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары белән расланган тәртиптә 2017 елның 15 маенда 09.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында, Г.Закиров ур., 52 йорт адресы буенча муниципаль район Башкарма комитеты бинасының актлар залында гавами тыңлаулар уздырырга.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның алар турында фикер алышуда катнашу тәртибен расларга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2017 елның 12 маена кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына җибәрергә.

5. Түбәндәгеләрне бастырып чыгарырга:

– «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында ;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашу тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектының ачык тыңлауларын уздыру тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы А.И. Миңнекаевка йөкләргә.

Саба муниципаль
муниципаль районы                                        Р.Н. Минниханов

Кушымта Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Советының
2017 елның 12 апрелендәге 99
номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган**
**үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты**

**1.** Уставның 6 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында «каникуллар вакытында балаларның ялын оештыру» сүзләрен «каникул чорында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә, аларның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп, чараларны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

**2.** Уставның 7 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.»;

**3.** 19 статьяның 3 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) район Уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы конституцияләре яисә законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелү очракларыннан тыш;»;

**4.** Уставның 45 статьясындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Район Башкарма комитеты:»;

**5.** Уставның 45 статьясындагы 1 пунктының 7 пунктчасының унберенче абзацында «чаралар күрү үз вәкаләтләре чикләрендә» сүзләрен «федераль законнарда каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру,» сүзләренә алмаштырырга, «район территориясендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

**6.** Уставның 87 статьясындагы 3 пунктында икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында һичшиксез яңадан торгызу рәвешендә үзгәрешләр кертелгәндә, гражданнарның шул хакта фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.»;

**7.** Уставның 88 маддәсенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Район башлыгы район Советы рәисе вәкаләтләрен башкарган очракта, район башлыгының тавышы Район Уставын, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткәндә исәпкә алына.».